**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

**02.04.2018ел** **Яр Чаллы шәһәре** **№1091**

"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегенең 16: 39: 160702: 3452 кадастр номеры белән җир кишәрлеге территориясен планлаштыру һәм межалау проектын әзерләү турында»

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү мәсьәләләрен җайга салу максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, район Уставына таянып

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегенең 16: 39: 160702: 3452 кадастр номеры белән җир участогы территориясен планлаштыру һәм межалау проектын эшләүгә керешергә.

2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегенә әлеге карарны рәсми басмада («Якты юл» газетасы) бастырып чыгарырга, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында tukay.tatar.ru һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Ф. М. Камаев